**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ УРЫССУ ПОСЕЛОГЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**№ 9** **Урыссу ш. т. п.** **«01» 06 2021**

**Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 7.05.2014 ел, №5 "Җирле салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча недоимканы түләттерүне ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясы, Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 19.08.2010 ел, № ЯК-7-8/393@ Боерыгының 6 пункты нигезендә, ТР Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Советы КАРАР КАБУЛ ИТӘ:

1.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Советының 2014 елның 7 маендагы 5 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1 пунктта:

Икенче абзацта "өч елдан артык бурыч барлыкка килү датасы белән" сүзләрен төшереп калдырырга;

Өченче абзаң - "Мәрхүм булу датасыннан соң 6 ай дәвамында мирас хокукын белдермәгән очракта, үлгән физик затларга җир салымы һәм алар милкенә салым буенча" сүзләрен төшереп калдырырга;

Дүртенче абзац – “-җиргә салым һәм физик затлар милкенә салым буенча бурычларны өч елдан артык түләттерүгә ышанычсызлык барлыкка килү датасы белән һәр елдан соң килгән айның һәр 1 числосына” сүзләрен түбәндәге текстка алмаштырырга: “бурычлар барлыкка килү вакыты 3 елдан артык срок белән физик затларга җир салымы һәм милеккә салым, әлеге салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча;

Түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«-“Башкару производствосы турында” 02.10.2007 ел, № 229-ФЗ Федераль законның 46, 47 ст.1 өлешенең 3, 4 пунктларында билгеләнгән очракларда, башкарма документны түләтүчегә кире кайтару турында суд приставы тарафыннан карар чыгарганда җирле салымнар,пенялар һәм алар буенча штрафлар буенча”.

2. Әлеге карар үз тәэсирен бурыч барлыкка килгән мизгелдән булган хокук мөнәсәбәтләренә тарата.

3.Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Башлыгы -
шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Советы Рәисе А. Ә. Шәфигуллин